# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Физик культура һәм спорт турында" 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьядагы 9 пунктта "(допинг куллануга каршы гамәлләрне дә кертеп)" сүзләрен "(спортта допингны булдырмауны һәм аңа каршы көрәшне кертеп)" сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:
а) 1 пунктта "спорт федерацияләре," сүзләрен төшереп калдырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
"$1^1$) спорт федерацияләре;";

3) 6 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
"5) физик культура, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны гамәлгә ашыруда катнашырга.";

4) 10 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Республика спорт федерациясе, әгәр мондый федерация гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе булып торса, юридик зат хокукына ия була алмый.";

5) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"17 статья. **Спортта допингны булдырмау һәм аңа каршы көрәш**

Спортта допингны булдырмау һәм аңа каршы көрәш федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.";

б) 18 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Спортчының физкультура-спорт оешмасына каравы спортчы һәм физкультура-спорт оешмасы арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе нигезендә һәм (яисә) спортчының иҗтимагый оешма яисә иҗтимагый-дәүләти оешма оештыру-хокукый рәвешендәге физкультура-спорт оешмасында әгъза булуы нигезендә билгеләнә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 22-ТРЗ